ГЛАВА
ДРОЖЖАНОВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЧҮПРӘЛЕ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШЛЫГЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

22.05.2026 с.Старое Дрожжаное №21

Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы җирле үзидарә органнарында шәхси белешмәләрне эшкәртү иминлеге сәясәтенә үзгәреш кертү турында

«Шәхси мәгълүматлар турында» Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында» һәм «Россия Федерациясе субъектында – федераль әһәмияттәге Мәскәү шәһәрендә ясалма интеллект технологияләрен эшләү һәм гамәлгә кертү өчен кирәкле шартлар тудыру максатларында махсус җайга салу экспериментын үткәрү турында һәм «Шәхси мәгълүматлар турында» Федераль законның 6 һәм 10 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» 2024 елның 8 августындагы 233-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, КАРАР БИРӘМ:

1. Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Башлыгының 2020 елның 30 декабрендәге 51 номерлы (29.09.2022 № 30 редакциясендә) карары белән расланган Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы җирле үзидарә органнарында шәхси белешмәләрне эшкәртү иминлеге сәясәтенә, **6.2 пунктын** түбәндәге эчтәлекле **3.1 пунктчасы** белән тулыландырып, үзгәреш кертергә:

«3.1) мәгълүматны юк итү функциясен үз эченә алган, мәгълүматны саклау чараларының тәңгәллеген бәяләү процедурасын билгеләнгән тәртиптә узган шәхси мәгълүматларны юк итү өчен куллану;».

2. Әлеге карар рәсми басылып чыгарга тиеш.

Башлык М.Р. Гафаров